# Регионда печән һәм сенаж әзерләv бара



Мордовия хужалыклары мал-туарга азык әзерли.
Бар булган исәпләvләр буенча, җәмәгать терлекчелегенә азык әзерләv сезонында, туклыклы кышлауны тәэмин итv очен, республика авыл хужалыгы предприятиеләренә һәм фермерларына 94 мен тонна печән, 650 мен тонна сенаж, 750 мен тонна силос әзерләргә туры киләчәк. Ләкин бу-минималь программа. Реаль исәп-хисап ел ярымга азык запасы белән.      Шул ук вакытта ин моһим бурыч – югары сыйфатлы азык әзерләv. Бу максатка нәкъ менә азык культураларын иртә вакыт эчендә жыеп алу һәм алардан азык әзерләv технологиясен vтәv ярдәм итә. Мәсәлән, Ләмберә районы Николаевск бvлеге идарәчесе Сергей Агафонов ирешкән нәтижәдән канәгать:
- Без һава торышы биргән барлык остенлекләрдән файдалана алдык. Эш биш кон генә дәвам итте. Бу вакытта басуларда 10 берәмлек техника һәм силос салуда 3 берәмлек техника жәлеп ителә. Нәтижәдә, эшләр вакытында башкарылган. Без 2000 тоннадан артык сенаж салдык.
Эш темплары һәм сыйфаты заманча техника белән тәэмин ителгән. Механизаторлар яна тракторлар һәм Ватан житештергән комбайннар кулланганнар. Әмма башкаручылар vзләре дә аз олеш кертмәгән.
Сенаж әзерләv тәмамлангач, хужалык тырышлыгы язгы культураларны сиптерvгә юнәлтелгән.
Ә Чамзинка районы берьеллык vләннәрдән азык әзерләvгә керешкән лидерлар очлегенә керә. Кvпьеллык vләннәрне жыю тәмамлана, планлаштырылган 2 872 гектардан 2 451 гектар мәйданда кvпьеллык vләннәр чабылган, шулардан 17 896 тонна сенаж, бу 2023-2024 елларнын кышлау очен азык әзерләv планынын якынча 50% тәшкил итә. Бу эшләр белән параллель рәвештә чvп vләннәреннән, корткычлардан һәм авырулардан авыл хужалыгы культуралары чәчvлекләрен эшкәртv актив алып барыла. Моннан тыш, Чамзинка аграрийлары республикада беренчеләрдән булып берьеллык vләннәрне жыюга керештеләр. Бvгенге кондә әлеге культуранын 40% чамасы кырылган, дип хәбәр итә Мордовиянен Минсельхозпроды.

**Н.ХӘЛИЛ**